Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы карары
19.07.2013 ел №14

**Сарман мунципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

Иске Минзәләбаш авылы

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы

КАРАР № 14

Иске Минзәләбаш авылы 19.07.2013 ел

**Сарман мунципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге уставын гамәлдәге закон нормаларына туры китерү максатында һәм Сарман районы прокурорының 21.03.2013 ел, №02.7-01/13 протесты белән бәйле рәвештә Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгыА.Р. Мияссәровага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш
авыл җирлеге Советы рәисе А.Р. Мияссәрова

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш
авыл җирлеге Советының
2013 елның 19 июленнән 14нче номерлы
карарына кушымта

**Сарман мунципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге**
**Уставына үзгәрешләр кертү**

1. 7нче маддәнең 1нче өлешендәге 18нче пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә: «, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны тикшереп карап чыгуны башкару һәм тикшерү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында тәкъдим ясарга».

2. 7.1 нче маддәнең 1нче өлешендәге 4нче пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. 7.1 нче маддәнең 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 11 пункт белән тулыландырырга:

"11) "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларга ярдәм күрсәтү».